ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 29 октябре №584

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «мәгариф идарәсе» МКУ составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында 2022 елның 6 апрелендәге 530 номерлы (12.05.2025 № 258 редакциясендә)карарына үзгәрешләр кертү турында

«, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручыларга Татарстан Республикасы «исем» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында"Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 530 номерлы (2025 елның 123 маендагы 258 номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

2 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең нигез окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (җитәкчесе) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик | - | - | 24598,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | | | |
| | Структур бүлек мөдире (башлыгы) : муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | | | 24690,0.». |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче А.Ю.Сәлимов